

Беренче тапкыр “Ел гаиләсе” бәйгесен РФ Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы, Авыр хәлдә калган балаларга ярдәм итv фонды белән берлектә, 2016нчы елда оештырган. Конкурснын топ максаты - гаиләнен дәрәжәсен кvтәрv, гаилә кыйммәтләрен саклау. Үткән ел бәйгедә Россиянен 79 тобәгеннән 294 гаилә катнашкан. Жинvчеләрне 5 номинация буенча ачыклаганнар: «Кvп балалы гаилә», «Яшь гаилә», «Авылда яшәvче гаилә», «Россиянен алтын гаиләсе», «Гореф-гадәтләрне саклаучы гаилә». Рузаевка районында әле генә “Яшь гаилә – 2021” конкурсына нәтижә ясалды.      Гаилә, мәхәббәт һәм тугрылык конендә “Яшь гаилә – 2021” конкурсынын финалы булды. Жинvчеләре - Новиковлар гаиләсе: Айсылу, Иван һәм аларнын кызлары Азалия. Шулай ук “Тамашачы симпатиясе” номинациясендә - беренчеләр.

Мин Айсылу турында бераз язмый булдыра алмыйм, чонки аны татар теле һәм әдәбияты предметлары буенча олимпиадаларнын республика турларындагы жинvчеләр рәтендә кvрә идем. Якташыбыз Шәриф Камалга багышланган Юбилей кичәләрендә Айсылунын татар биюләрен матур биюен кvргәнем бар иде, Мордовиядә vткән “Татар кызы - 2018” конкурсы финалисткасы да ул; бер сvз белән әйткәндә – торле яктан сәләтле шәхес. Ә бvген vзе укыган Татар Пешләсе урта мәктәбендә, МГПУ (элекке М.Е.Евсевьев исемендәге педагогия институты) тәмамлап, рус теле һәм рус әдәбияты предметлары буенча укучыларга белем бирә. Бу бәйгенен район этабы турында мәктәп сайтында кvрә. Ойгә кайткач, гаилә кинәшмәсендә бу яналык турында сойләгәч, тормыш иптәше Иван Иванович бер дә икеләнмичә: “Әйдә, катнашабыз”,- ди. Шулай конкурска документлар кабул итvнен сонгы конендә (16 июньдә) гариза язып жибәрәләр. Бер коннән сон алар ярышнын беренче этабы булган фотосессия vтәргә тиеш булалар. Фотокорреспондент белән жюри әгъзалары ойләренә килеп бу турны vткәрәләр. Гаилә башы рус милли киемнәреннән, Айсылу - татар милли киемендә, ә кызлары Азалия – рус кvлмәге, татар тvбәтәе киеп тошкән фотолар конкурсантлар арасында “Тамашачы симпатиясе” призына лаек булалар.


ОТКРЫТЫЙ КОНКУРС
МОЛОДАЯ СЕМЬЯ